МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

15.05.2018 г.Казань №_261-осн_

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2010 елның 01 июлендәге 269-осн номерлы боерыгы белән расланган Арендаланган урман кишәрлекләре яки аренда хокуклары белән алыш-бирешләргә ризалык бирү турында документлар карау тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Урман мөнәсәбәтләрен җайга салучы законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә, **боерык бирәм**:

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2010 елның 01 июлендәге 269-осн номерлы боерыгы (2010 елның 3 ноябрендәге 478-осн номерлы, 2014 елның 12 февралендәге 38-осн номерлы боерыклар нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Арендаланган урман кишәрлекләре яки аренда хокуклары белән алыш-бирешләргә ризалык бирү турында документлар карау тәртибенә үзгәрешләр кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Үзе белән дәүләт мөлкәтендә яисә муниципаль мөлкәттә торучы урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе төзелгән конкурста җиңүче яисә конкурста бердәнбер катнашучы әлеге Кодексның 80.2 статьясының 10 өлеше нигезендә хокукларыннан чигенергә һәм аталган шартнамә буенча барлыкка килгән йөкләмәләргә бәйле бурычын күчерергә, шулай ук тапшырылган урман кишәрлеген субарендага тапшырырга хокуклы түгел.»;

2 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле 1.1 пунктча өстәргә:

«1.1) персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык (гражданнар, шул исәптән шәхси эшкуарлар өчен);»

8 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык (гражданнар, шул исәптән шәхси эшкуарлар өчен).»;

түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктын өстәргә:

«2.1. Арендатор документларны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәне яки мондый өземтәнең нотариаль таныкланган күчермәсен – юридик зат өчен, Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәне яки мондый өземтәнең нотариаль таныкланган күчермәсен – шәхси эшкуар өчен теркәмичә; салым органында салым исәбенә куелу турында таныклык күчермәсен һәм урман кишәрлегенең кадастр паспорты (планы) күчермәсен теркәмичә тапшырган очракта, ведомствоара зарызнамә буенча:

юридик затларны, физик затларны шәхси эшкуарлар һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары сыйфатында дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы мөрәҗәгать итүче турында белешмәләрнең юридик затларның бердәм дәүләт реестрына (шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына) кертелгән булу фактын раслаучы белешмәләрне бирә;

хокукларны дәүләт теркәвенә алуны, дәүләт кадастр исәбен, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып баруны гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы урман кишәрлегенең кадастр исәбенә куелу фактын раслаучы белешмәләрне бирә.

Документлар (белешмәләр) алу өчен ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша гарызнамәләрне җибәрү һәм аларны алу Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының аренда бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

2. Юридик бүлеккә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми сайтында (PRAVO.TATARSTAN.RU) рәсми рәвештә бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Бу Боерык үтәлешен контрольдә тотуны урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары Ә.Н.Бәдретдиновка йөкләргә.

Министр Р.Ә. Кузюров